ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сойки авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Сойки авылы
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Сюкеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Сюкеево
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№22** **07.09.2018г.**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 2 маендагы “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 2 маендагы 5 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Красноармейская ур., авыл үзәге;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сөйки авылы, Колхоз ур., йорт 16а, китапханә бинасы,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче В.П. Никитин